Шәһри КАЗАН

СИШӘМБЕ, 22 ГЫЙНВАР, 2013 ЕЛ,
N 8 (5186)
WWW.SHAHRIKAZAN.COM

1990 елдан бирле чыга

АРСТАН БАШКАЛАСЫНЫҢ КӨНДӘЛЕК ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ҺӘМ МӘДӘНИ ГАЗЕТАСЫ

2 бит

БУЛӘККӘ — ХОККЕЙ КИЕМНӘРЕ

3 бит

ЮГАРЫ СЫЙФАТ ЫШАНЫЧ ТУДЫРА

12 бит

«ДИКТАТОР ДА, КӨТҮЧЕ ДӘ БУЛЫРГА ТУРЫ КИЛӘ»

КӨН АВАЗЫ

Узган елны Удмуртия республикасында «Бураново әбиләре»нең, «Евровидение»дә чыгыш ясап, уңышка ирешкән көнен – 26 майны Әбиләр көне дип игълан иткәннәр иде. Быел әлеге көн уңаеннан анда әбиләргә багышланган һәйкәл куелачак.

* * *

Казахстанның Актау бала тудыру йортында яңа туган мөселман балаларына исем кушуны җайга салганнар. Анда балаларга исемне махсус бүлмәдә кушалар. Ана белән баланы өйләренә озатканда аларга балага исем кушу турындагы таныклык та бирелә.

* * *

Австралиядәгеләр эсселектән интегә. Узган атнада Сиднейда 74 ел элек булган температура рекорды кабатланган. Анда термометр баганасы 45,8 градуска кадәр күтәрелгән. Җирле метеоролог Бен Доменсино сүзләренчә, 40 градуслы температура соңгы 107 елда бары тик дүрт тапкыр гына күзәтелгән. Моңа бәйле рәвештә, янгыннар саны да арткан.

* * *

Кытайның Шанхай шәһәрендә күпләрнең күңеленә хуш килерлек парк ачылган. Эш шунда – андагы бөтен әйбер дә шоколадтан. «Бакыр» статуя да, йозак та шоколадтан эшләнгән. Соңгысына барысы 160 тонна какао киткән.

* * *

Сочида узасы Олимпиада билетларының бәяләре билгеле булды. Иң кыйммәтлесе хоккей турниры финалы булачак икән. Аңа билетлар 40 меңгә кадәр җитәчәк. Фигуралы шууны яратучыларга да кесә ягын алдан кайгыртып кую мәслихәт. Анда керер өчен кимендә – 1,5 мең, иң күп дигәндә 23 мең сораячаклар.

УНИВЕРСИАДА — ГАИЛӘ БӘЙРӘМЕ

2 бит

КҮП БАЛАЛЫЛАРГА ҖИР БИРҮ ДӘВАМ ИТӘ

«ШК» газетасының 24 гыйнвар — пәнҗешәмбе санына алхәбәр

«Яңа Тура»да сату-алу өчен бөтен шартлар да бар, барам дисәң, автобусы да бушлай. Тик шулай да гади сатып алучы, шул ук олы яшьтәге әби-апаларыбыз анда кадәр барып йөрерләрме икән — менә монысы шик тудыра.

Чулпан НӘҖИПОВА. «Казандагы базарлар «Яңа Тура»га күченде»

5 бит

Күп тә үтмәде, минем яныма участковый килеп җитте. «Ник син намазларыңны бабайларча укымыйсың?» — дип сорый бу миннән. Тәмам аптырап калдым, нәрсә әйтергә, нәрсә уйларга белмим.

Сөләйман ӘБЗӘЛИМОВ. «Шуны да белмәгәч, ник мәчеткә килдең?»

7 бит

2013 елны «Азатлык» татар яшьләре берлеге Бату хан елы дип игълан итте. Бу уңайдан әле беренче урам чарасы оештырылырга өлгермәсә дә, мәгълүмат кырында, интернет форумнарда шау-шу башланды.

Фәнил ГЫЙЛӘҖЕВ. «Бату хан атының тояклары бөтен Европаны тетрәткән»

10 бит

ОЧТЫ–КИТТЕ

ӘЙТКӘН СҮЗ — АТКАН УК

Илсур МЕТШИН,
Казан мэры:

— Универсиададан соң кадрлар үзгәреше кертмичә булмас, мөгаен. Чөнки кайбер җитәкчеләрнең тиреләре нык калынайды.

(«Эшлекле дүшәмбе» киңәшмәсендә шәһәрдәге төзелешләрнең акрын башкарылуын тәнкыйтьләгәндә әйткән сүзләре)

«Шәһри Казан»да бергә кайныйк! Телефоннарыбыз: (843) 562-50-07 (факс), 562-50-12

РӘСМИ ХӘБӘРЛӘР

Эшчәнлеге өчен бүләкләнде

КАЗАН Кремлендә АКШта яшәүче татар галимен хөрмәтләделәр.

Күптән түгел 80 яшьлек юбилеен билгеләп үткән академик Роальд Сәгъдиевкә ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов «ТР каршындагы казанышлары өчен» орденын тапшырды. Дөньякүләм танылган татар галиме, Россия һәм Татарстан Фәннәр академияләре академигы, физика-математика фәннәре докторы, АКШның Мэриленд штаты университеты профессоры, әлеге уку йортының «Көнчыгыш-Көнбатыш» фәнни тикшеренүләр үзәген җитәкләүче Роальд Сәгъдиевкә 80 яшь узган елның декабрь азагында тулды. Бу көннәрдә галимнең тарихи ватаны Татарстанда шул уңайдан юбилей чаралары уза. Роальд Сәгъдиев республиканың әлеге югары бүләгенә озак еллык фидакарь хезмәте, плазма физикасы проблемаларын тикшерүгә керткән зур өлеше, киңкырлы җәмәгать эшчәнлеге өчен лаек булды.

Форум бездә узачак

КАЗАН 2015 елда Каталитик химия буенча халыкара конгрессны үзендә уздыру хокукын яулады.

Каталитик химия буенча зур әһәмияткә ия булган фәнни форум – Катализ буенча халыкара конгресс 2015 елда Казанда узачак. Россия мондый дәрәҗәле фәнни чараны үзендә соңгы 20 ел эчендә беренче тапкыр кабул итә, дип хәбәр итә Россия фәннәр академиясенең Себер бүлеге матбугат хезмәте. Боресков исемендәге катализ институты директоры Валентин Пармон сүзләренчә, Россия баштарак, инфраструктуралары тиешенчә үсмәгәнлектән, конгресс уздыру урыны итеп каралмаган булган. Гадәттә Европа конгрессы эшендә бер үк вакытта 1,5 мең тирәсе кеше катнаша икән. Казанның Универсиадага әзерләнүе нәтиҗәсендә, шәһәрдә мондый зур дәрәҗәдәге чараны уздыру өчен дә тиешле шартлар барлыкка килде, дип билгеләп үткән галим.

Әлфия Афзаловага — машина

Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты Әлфия Афзалованың юбилей кичәсе узды.

Мәдәният министры Айрат Сибагатуллин җырчыга ТР Президенты исеменнән машина ачкычы тапшырды. Флюра Сөләйманова, Салават Фәтхетдинов, Зөһрә Шәрифуллина, Рафаэль Ильясов һәм башкалар легендар җырчыга үзләренең тәбрикләүләрен җыр аша җиткерделәр.

СОРАШТЫРУ

Кочаклашыгыз, җәмәгать!

Кичә бөтен дөньяда гадәти булмаган бәйрәм – Халыкара кочаклашу көне билгеләп үтелде. Әлеге көн иң беренче булып Америкада барлыкка килгән, аннары бөтен дөньяга таралган. Бәйрәм традициясе буенча, бу көнне таныш булмаган кешене дә кочакларга киңәш ителә. Ә сез кочаклашырга яратасызмы?

Мөслимә ШӘФЫЙК, журналист:

– Бик нык яратам. Кочаклашуны медицина да хуплый. Якын кешеләреңне иркәләп кочаклау тән җылысын гына түгел, күңел җылысын да бирә. Ул бербереңә тагын да якынайта. Бәләкәчләрне дә аркаларыннан сөеп кысып кочакласаң, кәефең күтәрелә. Мин үзем бөтен кешене дә диярлек якын күреп кочакларга яратам. Яшьләр кочаклаша инде анысы, безнең кебек олы буын кешеләренә, бик күп еллар бергә гомер иткән карчык белән картларга да кочаклашырга кирәк.

Галимҗан ГЫЙЛЬМАНОВ, язучы:

– Кочаклашу безнең әнкәйдән килә. Авылга кайткан саен, без аның белән кочаклашып күрешәбез, кочаклашып саубуллашабыз. Кочаклап аркадан кагып куюу ул безнең бер милли гадәтебез дә кебек тоела миңа. Чөнки ул гади кочаклау гына түгел, кешегә хөрмәт билгесе дә. Дустыңның аркасыннан кагып кую арадагы ышанычлылыкны, татулыкны күрсәтә. Тик теләсә кемне кочаклау безгә хас нәрсә түгел.

Азат СӘЛАХОВ, газета укучы:

– Ә кем яратмый? Хатынны да, балаларны да, мәчебез Йомшаккайны да кысып кочаклыйм. Балаларны дигәннән, әле бер көнне генә телевизордан бер психолог балаларны еш кочакларга-яратырга кушты. Яратү җитмәгән баланың иммунитеты начар була икән.

КАЗАН ХӘБӘРЛӘРЕ

Күп балалы гаиләләргә җир бирү дәвам итә

Бушлай бирелүче җир кишәрлегеннән өч мәртәбә баш тарткан яки җир кишәрлеген сайлап алу чарасына өч мәртәбә килмәгән кеше исемлектән сызыла.

СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ

Дамир БӘДРИЕВ

«Эшлекле дүшәмбе» киңәшмәсендә шәһәр башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Рөстәм Нигъмәтуллин әнә шундый кисәтү ясады. Әмма гаиләнең җир кишәрлеге сорап кабат җирле үзидарә органнарына мөрәҗәгать итү хокукы саклана.

Барлыгы 4365 гариза теркәлгән, шулардан 3830 гаилә бушлай җир кишәрлеге алу хокукы расланылган исемлеккә кертелгән. Рөстәм Нигъмәтуллин сөйләгәнчә, Биектау районының Каймары авылы янәшәсеннән Казанның 811 гаиләсе шәхси йорт төзү өчен җир алган инде. 1 нче комплекста кишәрлекләр беткән, хәзер 2 нче һәм 4 нче комплекслардан кишәрлекләрне сайлап алу бара. Мәгълүм булганча, ASG компаниясе муниципаль карамакка 300 гектар җирен күчергән иде. Каймары авылы янында күп балалы гаиләләр яшәячәк 1735 йорт барлыкка киләчәк. «Кишәрлекләрнең гомум саны – 1952, буш калган урыннарда социаль учреждениеләр төзеләчәк», – диде Рөстәм Нигъмәтуллин.

Күп балалы гаиләләргә җир кишәрлекләре Лаеш районының Сокуры авылы янәшәсеннән дә бүленә. Шәһәр башкарма комитеты әлеге максатлар өчен «Ак Барс» компанияләр төркеменнән һәм «Татфондбанк»тан 166 гектар җирне муниципаль милеккә алды. Монысында 960 кишәрлек планлаштырылган. Сокуры авылы янәшәсендә «Ак Барс Банк» ачык акционерлык җәмгыяте карамагындагы тагын 100 гектар җирне күп балалы гаиләләргә тапшыру мәсьәләсе тикшерелә.

Мэр Илсур Метшин: «Россиядә шактый шәһәрләр, буш җирләр юк, дип, күп балалы гаиләләргә җир кишәрлекләре бирү чарасының үтәлешен шик астына куйдылар. Казан бу очракта да әйдаман, гаиләләргә кишәрлекләр актив рәвештә өләшелә. 185 нче федераль законга охшаш закон кирәк. Ул күп балалы гаиләләр өчен барлыкка китерелгән яңа бистәләрдә инженерлык корылмалары төзүне бермәбер җиңелләштерәчәк. Югары органнарга шундый тәкъдим кертәчәкбез», – диде.

УНИВЕРСИАДА ачылышы тантанасы һәр гаилә өчен бәйрәм булсын

www.ria.ru

Бөтендөнья студентлар уеннары ачылышы тантанасы репетициясе 15 февральдән башлана.

УНИВЕРСИАДА СУЛЫШЫ

Казан мэры Илсур Метшин рәислегендә XXVII Җәйге Универсиаданың ачылу һәм ябылу тантанасына әзерлек штабы утырышы булды. Очрашуда оештыру мәсьәләләре һәм әзерләнә торган грандиоз шоуның ничек булачагы каралды. Иҗади коллективлар – балет һәм цирк төркемнәре, күп халык катнаша торган чараларда сәхнә артистларын сайлап алу эшләре төгәлләнгән. Универсиада ачылышында күрергә мөмкин булган төп номерларның репетициясе инде февраль уртасыннан ук башланачак икән. «Казань-2013» башкарма дирекциясе» оешмасының генераль директор урынбасары Игорь Сивов әйтүенчә, сайлап алынган коллективлар Казанның спорт комплексларында әзерләнәчәк. Шоуда җиде меңләп кеше катнашачак, ә ачылу тантанасы үзе дүрт сәгатькә сузылыр дип көтелә. Илсур Метшин фикеренчә, атаклы спортчылар һәм артистлар белән бергә яшь казанлыларны да мөмкин кадәр күбрәк катнаштырырга кирәк. «Универсиада ачылышы тантанасы Татарстандагы һәр гаилә өчен бәйрәм булсын иде», – дип билгеләп үтте ул. Тамашачыларның туксан проценты нәкъ менә шул тантананы караячак. Анынча, бу дөньяга Казан турында ишеттерүнең бер зур мөмкинлеге булып тора.

Исегезгә төшерәбез: Универсиада 6-17 июль көннәрендә узачак. Аны ачу тантанасы 45 мең тамашачыга исәпләнгән яңа стадионда булачак.

Стадионга исем эзлик

ИГЪТИБАР

«Татмедиа» басма һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгы Казанда 2013 елгы Универсиаданы ачу һәм ябу тантаналары, 2018 елда футбол буенча дөнья чемпионаты уеннары үткәрү өчен төзелә торган 45 мең урынлы стадион исеменә бәйге игълан итте. Бәйге ике этапта уздырыла. Аның беренче туры 18-24 гыйнварда үткәреләчәк. Аның кысаларында теләге булган һәркем электрон почта аша pr@tatar-inform.ru адресына («Татар-информ» агентлыгы – бәйгене оештыручы жаваплы) «Бәйгегә» дип язып, исем җибәрә ала.

Бәйгенең икенче этабы 25-30 гыйнварда уздырыла. Бу этапта «Татар-информ» сайтында беренче тур йомгаклары буенча тәкъдим ителгән стадион исемнәре өчен ачык тавыш бирү булачак.

Бәйгедә җиңүчегә стадионны ачу тантанасында кыйммәтле бүләк тапшыру күздә тотыла.

Бүләккә — хоккей киемнәре

КАЙГЫРТУ

Казанда «Сәламәтлек бишьеллыгы» программасы кысаларында спортка кагылышлы һәртөрле чаралар гамәлгә ашырыла.

«Ватан» спорт-сәламәтләндерү комплексының боз аренасында хоккей буенча «Алтын алка» турнирының алдынгы урыннар яулаган Авиатөзелеш һәм Яңа Савин районнары командаларын бүләкләү тантанасы булды. Районнарның депутатлар корпусы ярдәмендә балалар хоккей командаларына 1 миллион сумга якын бәядә хоккей киемнәре һәм бүләкләр тапшырылды. Авиатөзелеш һәм Яңа Савин районнары хакимияте башлыгы Тимур Алибаев, шәһәр башкарма комитетының спорт комитеты рәисе Илгиз Фәхриев яшь спортчыларга алга таба да уңышларга ирешүләрен теләделәр. Ахырда «Алтын алка» турниры финалчылары хоккей матчында көч сынаштылар.

ҖӘМГЫЯТЬ

Апрельдән чистара башлыйбыз

ТИКШЕРҮ



Республикада 1 апрельдән санитар чистарту буенча икеайлык башланып китәчәк. Бу Казанда июль аенда узачак Универсиадага әзерлек максатыннан үткәрелә. Икеайлыкка федераль хезмәтләр, хокук саклау органнары, административ-техник инспекция, Казан шәһәре хакимияте вәкилләрен актив җәлеп итү көтелә. ТР экология һәм табигый ресурслар министры Артем Сидоров хәбәр иткәнчә, Казанда әйләнә-тирә мохиткә зыян салучы предприятиеләр тикшереләчәк. ТР Министрлар Кабинетында ТРда Экологик культура һәм әйләнә-тирә мохитне саклау елына багышланган матбугат очрашуында Казанның зур сәнәгать предприятиеләрен инде тикшерү башланганлыгы хәбәр ителде. Министрлык һәм Казанның табигатьне саклау прокуратурасы хезмәткәрләре иң беренче «Казаноргсинтез» оешмасында булганнар. Тикшерү вакытында иң элек әйләнә-тирә мохиткә ясала торган тискәре йогынтының кимү-кимәмәвенә игътибар биреләчәк. Аерым алганда, һавага, суга чыгарыла торган зыянлы калдыклар исәпкә алыначак. Министр шулай ук ягулык-энергия ресурсларын кулланунын нәтиҗәлелеген арттыруга юнәлтелгән мөһим проектны тормышка ашыруның дәвам итәчәген дә билгеләп үтте. Сүз республиканың ягулык сала торган станцияләрендә (АЗС) мотор ягулыгының зарарлы парларын тотып калу юнәлешендә җиһазлар кую буенча республика программасын эшләү турында бара. Министрның сүзләренә караганда, бөтен АЗСлар 2020 елга кадәр мондый җиһазлар белән җиһазландырылырга тиеш. Беренче этапта ул Казан, Чаллы, Түбән Кама һәм Әлмәт шәһәрләрен, икенче этапта исә башка төбәкләрне дә колачлаячак.

Югары сыйфат ышаныч тудыра

ҮРНӘК

Зөлфия ХӘЛИУЛЛИНА

Руль артына утырган бер генә кеше дә бензинның сыйфатына битараф түгел. Шуңа да тезелеп киткән ягулык салу станцияләре арасыннан һәркайсыбыз сыналганын, ышанычлысын сайларга тырышабыз. Бензинның сыйфатына республика җитәкчелеге тарафыннан да зур таләпләр куела тора. Узган ел, Татарстан Президенты фәрманы белән, республикадагы ягуэнергетика ресурсларын дөрес куллану идарәсе 19 ноябрьдән 25 декабрьгә хәтле аралыкта ягулык салу станцияләрендәге бензинның сыйфатын тикшерү буенча эш алып барды. Барлыгы 511 ягулык салу станциясеннән 1092 проба алынган. Шулар эчендә «Татнефть» ААҖнең 74 ягулык салу станциясе дә керә. Алардан алынган 144 пробаның барысы да ГОСТ таләпләренә туры килә.

«Татнефть» исеме астындагы ягулык салу станцияләрендәге бензинның сыйфатлы булуы – компания өчен иң мөһим бурычларның берсе. Биредә нефть продуктларының сыйфатына күзәтчелек заманча җиһазлар һәм алдынгы технологияләр кулланып башкарыла. Сыйфат күзәтчелеге системасы күп баскычлы. Сатыла торган нефть продуктларының сыйфат таләпләренә төгәл килүен раслау өчен, «Татнефть» ААҖнең ягулык салу станцияләре челтәре АЗСларының иркеле сертификациясе системасында катнаша. Бу «Татнефть» ААҖнең үз-үзенә таләпчән булуын, ә куллanучылар өчен ышанычлы партнер икәнлеген күрсәтә.

Безнең кызлар эшлеклеләр, уңганнар

БӘЙГЕ

Мәскәүдә Хатын-кызлар Ассамблеясы кысаларында эшлекле хатын-кызларның «Успех-2012» VIII Бөтенроссия бәйгесенә йомгак ясалды. «Золотая птица» иҗтимагый танылу премиясе белән ТР инвестицияләр үсеше агентлыгы җитәкчесенең урынбасары, «Татарстан Республикасының эшлекле хатын-кызлары» төбәк иҗтимагый оешмасы президенты Лиана Сәетова бүләкләнде. Ул «Россиянең эшлекле хатын-кызлары арасында иң яхшы яшь вәкил» номинациясендә җиңде. Җиңүчеләр арасында тагын бер гүзәл зат – Фәридә Ковалева. Сервис халыкара колледжы директоры, «Татарстан Республикасының эшлекле хатын-кызлары» төбәк иҗтимагый оешмасы әгъзасы булган Фәридә Ковалева «Башлангыч һәм урта белем бирү өлкәсендә хатын-кыз – җитәкче» номинациясендә әлеге премиягә лаек булды.

Белешмә өчен: 2012 елның «Успех» VIII Бөтенроссия бәйгесе гаиләләргә ярдәм итү, халыкның финанс мәдәнияттен үстерү, тормыш сыйфатын яхшыртуда хатын-кыз катнашы куәтен ачу, төбәк үсеше мәсьәләләрен хәл итү буенча социаль программа кысаларында узды. Аның максаты – Россиянең яңа гасыр башы «эшлекле, социаль актив хатын-кызы» дәрәҗәсен күтәрү.

Хуш, Адлер ага!..

Адлер ага Тимергалин соңгы араларда бер дә интервью бирергә ашыкмады. «Бик авырып торам, озаклап сөйләшеп утырырлык җаең булса гына кил», – дигән иде ул миңа да матбугатка биргән соңгы әңгәмәсе алдыннан. «Шәһри Казан»да әлеге гамьле әңгәмә басылып чыккач та, зур рәхмәтләр әйтеп шалтыратты. Фантаст язучыбыз, интеллигент шәхес, киңкырлы фикер һәм гыйлем иясе Адлер абый белән бер күрешеп сөйләшү үзе бер гомер булган икән шул. Авырту-сызланулар аша булса да, кулы һәрчак каләмдә иде аның.



ХУШЛАШУ

Гөлнара ҖӘЛИЛОВА

Күп кенә сүзлекләр төзүдән, мәктәп дәреслекләре тәрҗемә итүдән тыш, күпме әдәби әсәр, фантастика жанрындагы мирас калдырган әдип иде ул Адлер абый. «Роберт, уян сөеклем!» дип аталган беренче хикәядән башланган иҗат безгә – татар укучысына нинди генә китаплар дәвамы булып барып ирешмәде. «Кохау ронгоронго», «Адашкан йолдыз», «Таш алиһә» һәм башка китапларын, мавыктыргыч сюжетлы, мажаралы-фантастик өслүбтәге хикәя һәм повестьларны кайсыбыз гына кызыксынып укымадык икән?! Андагы әхлакый нигезләр, гуманистик карашлар кайсы бала психологиясенә уңай тәэсир итми калган икән?

Сарман районының Иске Минзәләбаш авылында туып-үскән әдибебез үзе дә укытучы гаиләсендә тәрбияләнгән шәхес. Казан дәүләт университетының физика-математика факультетында, астрономия бүлегендә белем ала ул. Аннан укуын шул ук юнәлештә Ташкентта дәвам итә. Соңрак укытучы, Казанга килгәч, Пионерлар йортында фәнни-техник түгәрәк җитәкчесе булып эшләп ала. Аннан Адлер абыйның хезмәт юлы озак еллар буена китап белән бәйле – ул Татарстан китап нәшриятында редактор вазифасын башкара.

Шуңа да соңгы очрашуыбыз – интервьюга дип әдип йортына килгәч, фатирның бөтен барлыгын колачлап алган китап галиҗәнапларының күплегенә гаҗәпләнмәдем дә. Адлер абый мине алар белән таныштырып, и-и, әле моның артысыннан артыгы да юк, таратып бетердем, туган якка җибәрдем, дип елмайган иде. Аның иплеитагатьле булуына, инде туксанынчы дистәне ваклый башлавына карамастан, ачык фикерләвенә, дөньякүләм һәм татар әдәбияты белән бер адымда баруына шаккатып, сокланып кайткан идем. Адлер абый исә 82 яшен тутыруга арабыздан китәргә ашыкты...

Авыр туфрагың җиңел булсын, Адлер ага! Син халык күңелендә зыялы, зур иҗади байлык калдырган олуг әдип булып сакланырсың. Хезмәтләрең, мавыктыргыч әдәби әсәрләрең сине һәрчак безнең арада итәр...

ФӘНИС МОТЫЙГУЛЛИН

Ыгы-зыгылы Грузия

Тавык боты күргән саен, Буш искә төшкән кебек, ә инде Грузия дию белән, галстугын чәйнәүче Саакашвили күз алдына килә дә баса инде. Соңгы биш елда әлеге илнең эчке-тышкы сәясәте, президентының кыланмышлары турында күп сөйләнде, бу постны башка берәү биләгән очракта да аны бөтенләй үк онытып бетермәячәкләр әле. Саакашвили президентлык иткән чорда истә калырлык һәм халыкара мөнәсәбәтләргә кискен үзгәрешләр керткән вакыйгалар аз булмады.

Көрәшчеләр ярдәме белән

Теге яки бу хакимнең шәхси көрәшчеләре булганлыгы тарихтан мәгълүм. Саакашвили да моннан читтә калмаган, күрәсең. Өч сигезле санының нинди илаһи көчкә ия икәнен әйтә алмыйм, әмма нәкъ менә 2008 елның 8 августында (08.08.08) грузин гаскәрләре Абхазия белән Көньяк Осетиягә бәреп кергән иде. Шул ук көнне Пекинда җәйге Олимпиада башланып китте, кытайлар аның ачылу көнен берничә ел алдан тәгаенләштергән булганнар. Кытайлар фикеренчә, 8 саны – чиксезлек билгесе. Саакашвили өчен бу сан нинди әһәмияткә ия – кистереп әйтү кыен, әмма шушы вакыйгалардан соң башланып киткән ыгы-зыгының игечиге әлегә, дөрестән дә, күренми.

Саакашвилига ун көн вакыт

Грузия Конституциясе буенча, дәүләт башлыгы биш елга сайлана. М.Саакашвилиның әлеге срогы 20 гыйнварда тәмамланды. Әмма сайлау кодексына кертелгән үзгәртүләр нәтиҗәсендә, киләсе сайлаулар октябрьдә генә узачак. Шул рәвешле, Саакашвили тагын ун ил белән идарә итәргә җыена. Тик моның белән килешмәүче һәм аның отставкага китүен таләп итүче өч меңгә якын кеше Президент йорты каршына митингка җыелды. Үз эченә җитмештән артык дәүләти булмаган оешма һәм партияләрне берләштерүче «Бердәмлек» коалициясе ике ай эчендә президентка каршы ике миллионнан артык имза җыйган.

Әмма Саакашвили отставкага китәргә уйламый, аның фикеренчә, бу акцияләр яңа хөкүмәт тарафыннан оештырылган. Акциядә катнашучылар аңа ун көн вакыт биргән, үзгәрешләр булмаган очракта, алар сүзләренчә, әлеге акциягә ил тулысынча кушылачак.

Җавап бирәселәр алда

Россиянең Европа Советы парламенты ассамблеясы (ПАСЕ) делегациясе Саакашвили президентлык иткән чорда Грузиядә кеше хокукларын бозу буенча доклад әзерләүне таләп итә. Дәүләт Думасының халыкара эшләр буенча комитеты рәисе А.Пушков әйтүенчә, сессиядә М.Саакашвилига сораулар күп булачак. «Грузия оппозициясе белдергәнчә, бик күп хокук бозу очраклары ачыклана – төрмәләрдә җәзалаулар, апрель демонстрациясеннән соң өй чардагында дүрт мәет табылу. Моңардан тыш Грузиянең элеккеге премьер-министры үтерелүне тикшерүнең аңлашылмаган нәтиҗәләре буенча да сораулар бар», – ди Пушков.

Шул ук вакытта Грузия делегациясе эчендә таркалу бара. Оппозиция вәкилләре, җинаять кылынган очракта алар тикшерелергә тиеш, дип исәпли.

Бар нәрсә дә Грузиянең үзеннән тора

Беларусь президенты А.Лукашенко Грузияне БДБга кире кайтару буенча бу ил җитәкчелеге белән сөйләшергә җыена. Аның әйтүенчә, Берләшмә – Грузия ихтыяҗы зонасы. Әмма әлегә Грузия җитәкчелегенең бу юнәлештә хәрәкәт итәргә атлыгып торуы сизелми. Лукашенко фикеренчә, Грузияне Көнбатыш тотып тора. Хәзер бар нәрсә дә Грузиянең үзеннән тора: теләк булганда, бер өстәл артына утырып, уртак проблемаларны, шул исәптән Грузия проблемалары хакында да сөйләшеп була.

Россиянең Куркынычсызлык Советы секретаре Н.Патрушев исәпләвенчә, Россия белән мөнәсәбәтләрне яхшырту өчен беренче адымны Грузия җитәкчелеге ясарга тиеш. Хәзер Грузиядә сәяси хәл авыр, илгә АКШ белән НАТОның йогынтысы зур.

Билгеле булганча, узган елның октябрендә парламент сайлауларында «Грузия хыялы» җиңеп чыккан иде. Аның җитәкчесе Иванашвили (хәзерге премьер-министр) белән Саакашвили кайбер мәсьәләләрдә тарафдарлар булсалар да (НАТО белән Евросоюзга керү), Россия белән мөнәсәбәтләрне яхшырту буенча алар төрле фикердә. Уртак тел тапмый торып, бу илдә тулысынча тынычлык урнашыр дип өметләнергә урын юк. Ул чагында бәлки Грузиянең Президенты да башка булыр инде.

Казан шәһәре башкарма комитеты карары 18.01.2013 №521

КАЗАН ШӘҺӘРЕ ТЕРРИТОРИЯСЕНДӘ САЙЛАУ УЧАСТОКЛАРЫ ОЕШТЫРУ ТУРЫНДА

2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 19 нчы маддәсе һәм 2012 елның 2 октябрендәге 157-ФЗ номерлы ««Сәяси партияләр турында» Федераль законга һәм «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның 4 нче маддәсендәге 7 нче өлеше нигезендә **карар бирәм:**

1. Казан шәһәре территориясендә, әлеге карар кушымтасына таянып, 412 сайлау участогы оештырырга.
2. Әлеге карарны «Казанские ведомости» һәм «Шәһри Казан» газеталарында бастырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче А.В.ПЕСОШИН

Казан шәһәре башкарма комитетының 2013 елның 18 гыйнварындагы 521 нче номерлы карарына кушымта

КАЗАН ШӘҺӘРЕ ТЕРРИТОРИЯСЕНДӘ САЙЛАУ УЧАСТОКЛАРЫ ДИСЛОКАЦИЯСЕ

АВИАТӨЗЕЛЕШ РАЙОНЫ

1 нче сайлау участогы
Сайлаучылар саны – 2864

Үзәге – «60 нчы номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль мәгариф учреждениесе, Граничная урамы, 2 йорт, тел. 570-85-97

Сайлау участогына керәләр: Сухая Река торак массивына караган 2 нче Большая, Большая Заречная урамнары, Вересаев урамы, 45-107, 2-104 йортлар, Верхоянск урамы, 43-139, 50-148 йортлар, Граничная урамы, 19-33 йортлар, 2 нче Заречная, Камчатка, Колхоз, 2 нче Колхоз, Луговая урамнары, Лянгузов урамы, 3, 4, 10, 15а, 16а, 21, 22 йортлар, Малая Заречная, Односторонняя Луговая, П.Баранов, Песочная урамнары, Песочный тыкрыгы, Песчаная, Пихта, 1 нче Полевая, Аркылы Колхоз, Поперечно-Луговая, Поперечно-Песочная урамнары, Пржевальский урамы, 1-31 йортлар, Придорожная, Пролетар, Промышленная, Речная, Сахалин урамнары, Северополюсная урамы, 6а, 7, 9а, 10а, 14а йортлар, 1 нче Сосновая, Сухая, Сухая Река урамнары, Ударная урамы, 3-21, 4-24 йортлар, Челюскин урамы, 114-132 йортлар.

2 нче сайлау участогы
Сайлаучылар саны – 2635

Үзәге – «60 нчы номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль мәгариф учреждениесе, Граничная урамы, 2 йорт, тел. 570-85-97

Сайлау участогына керәләр: Сухая Река торак массивына караган А.Кунанбаев урамы, 10-32, 11-29 йортлар, Вересаев урамы, 1-41 йортлар, Верхоянск урамы, 1-41, 2-48а йортлар, Вологодск, Гомель, Горбунов урамнары, Граничная урамы, 3, 14-24 йортлар, Донецк урамы, 26/41-42, 47/43-69/52 йортлар, Ишим урамы, Караганда урамы, 73-107/6, 62/49-96/4 йортлар, Керчь урамы, Литвинов урамы, 1/31-27, 6/23-26 йортлар, Луначарский урамы, 4, 8, 10 йортлар, Лянгузов урамы, 24а-68, 27-85 йортлар, Мариуполь урамы, 43-115/3, 38/53-114 йортлар, Яңа Каравай урамы, 7-47а, 12-54 йортлар, Нурлат урамы, 23/37-31/44, 46-54/52 йортлар, Поперечно-Большая урамы, Пржевальский урамы, 33а, 35 йортлар, Сарапул урамы, Северополюсная урамы, 17а, 18а, 19а, 21а, 26, 26а, 28а, 39, 45, 61, 63, 65 йортлар, Собинов урамы, 19-37, 26-44 йортлар, Соликамск урамы, Ударная урамы, 27-45а, 28-46 йортлар, Үзәк Мариуполь урамы, 86-156 йортлар, Чапаев урамы, 51-55 йортлар, Челюскин урамы, 75-109, 68-108/13, 110а, 101а, 103а, 105а, 109а, 111-135 йортлар, Л.Черкасов урамы, 1-35/69, 2-38 йортлар.

3 нче сайлау участогы
Сайлаучылар саны – 2440

Үзәге – «77 нче номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль мәгариф учреждениесе, Айдаров урамы, 2 йорт, тел.: 570-84-28, 570-86-68

Сайлау участогына керәләр: Лукин урамы, 53, 55 йортлар, Пржевальский урамы, 2, 4 йортлар.

4 нче сайлау участогы
Сайлаучылар саны – 2246

Үзәге – «123 нче номерлы һөнәр лицее» башлангыч һөнәри белем бирүче дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе, Дементьев урамы, 39 йорт, тел. 510-94-68

Сайлау участогына керәләр: Академик Павлов урамы, 1, 6, 8, 10, 9-13б, 17, 34-46а йортлар, Годовиков урамы, 12а, 13, 16а, 17, 19, 29а-79, 14а, 20-58 йортлар, Молодежная урамы, 3 йорт, Тамбов, Циолковский, Чайковский урамнары.

5 нче сайлау участогы
Сайлаучылар саны – 2549

Үзәге – «54 нче номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль мәгариф учреждениесе, Айдаров урамы, 10 йорт, тел.: 571-49-70, 570-85-77

Сайлау участогына керәләр: Айдаров урамы, 18/57, 20, 22, 24, 24а йортлар, Северополюсная урамы, 30 йорт, Челюскин урамы, 66, 68а йортлар.

6 нчы сайлау участогы
Сайлаучылар саны – 2408

Үзәге – «54 нче номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль мәгариф учреждениесе, Айдаров урамы, 10 йорт, тел. 571-00-07

Сайлау участогына керәләр: Айдаров урамы, 2, 8, 12, 14, 15, 15а, 16, 25, 25а, 27а, 29а, 31а йортлар, Ленинград урамы, 45а, 49а, 51а, 53а, 55а, 57а йортлар, Яңа Каравай урамы, 1, 2, 3, 3а, 4, 4а, 5, 6, 8, 8а, 10 йортлар, Нурлат урамы, 16-22 йортлар, Симонов урамы, 14/41, 16 йортлар, Чапаев урамы, 25-47, 24, 26, 28, 42-44 йортлар, Челюскин урамы, 60, 60а, 62, 64 йортлар, Челюскинчылар урамы, 44а йорт.

7 нче сайлау участогы
Сайлаучылар саны – 2430

Үзәге – «26 нчы номерлы лицей» муниципаль мәгариф учреждениесе, Ленинград урамы, 30 йорт, тел. 571-15-60

Сайлау участогына керәләр: Ленинград урамы, 22 йорт, 2 нче Ленинград урамы, 8-14 йортлар, Лукин урамы, 1, 5, 7, 7а, 9а, 11 (1, 2 корпуслар), 11а, 15 йортлар, Максимов урамы, 27а, 29, 31, 33 йортлар, Побежимов урамы, 24 йорт.

8 нче сайлау участогы
Сайлаучылар саны – 2689

Үзәге – «54 нче номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль мәгариф учреждениесе, Ленинград урамы, 28 йорт, тел. 571-00-07

Сайлау участогына керәләр: Ленинград урамы, 32, 32а, 34, 34а йортлар, 2 нче Ленинград урамы, 48, 50 йортлар, Лукин урамы, 17, 18, 20, 42а, 46, 48 йортлар, Малая Печерская урамы, Симонов урамы, 2б, 6, 43, 45, 47/50 йортлар.

9 нчы сайлау участогы
Сайлаучылар саны – 2350

Үзәге – «119 нчы номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль мәгариф учреждениесе, Максимов урамы, 76 йорт, тел. 571-11-66

Сайлау участогына керәләр: А.Кунанбаев урамы, 3-9, 4-10а йортлар, Айдаров урамы, 37-71а, 26-52/58 йортлар, 1 нче Армавир урамы, 1а-9, 2/35-16 йортлар, 3 нче Армавир урамы, 3-11а, 4-10 йортлар, Балтыйк урамы, 3-27, 2/19-28а йортлар, Беломорск урамы, 21а-37в, 26-56/26 йортлар, М.Бигиев урамы, 1-27/68, 4-28а йортлар, Верещагин урамы, Донецк урамы, 3-47а, 4-24 йортлар, Караганда урамы, 19-71а, 73а, 12/13-62а йортлар, Максимов урамы, 49, 58-82/20 йортлар, Мариуполь урамы, 1/44-41а, 2а-36в йортлар, Нурлат урамы, 5-19/35 йортлар; Грабарский торак массивына караган Аркылы Әстерхан урамы, 21-35, 22 йортлар, Аркылы Беломорск, 1 нче Аркылы Караганда, 2 нче Аркылы Караганда, Аркылы Шатура урамнары, Пришвин урамы, 3-13, 4-14 йортлар, Северополюсная урамы, 32, 34, 40, 40а йортлар, Үзәк Мариуполь урамы, 22-84а йортлар, Шатура урамы, 81/16-109а, 32-54/42 йортлар, Нурлат тыкрыгы.

10 нчы сайлау участогы
Сайлаучылар саны – 2706

Үзәге – «119 нчы номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль мәгариф учреждениесе, Максимов урамы, 76 йорт, тел. 571-11-66

Сайлау участогына керәләр: Караганда урамы, 6, 6а йортлар, Побежимов урамы, 46, 59 йортлар, Челюскин урамы, 25а, 27, 27а, 29, 31 йортлар.

11 нче сайлау участогы
Сайлаучылар саны – 2778

Үзәге – «117 нче номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль мәгариф учреждениесе, Дунай урамы, 16 йорт, тел. 571-41-64

Сайлау участогына керәләр: Беломорск урамы, 5, 11, 13, 17 йортлар, Ленинград урамы, 25/36 йорт, Максимов урамы, 40, 40а, 48 йортлар, Чапаев урамы, 12, 13, 14/7, 16, 15, 17 йортлар, Челюскин урамы, 33/56, 35, 38, 40/15, 42, 42а, 50, 52 йортлар.

12 нче сайлау участогы
Сайлаучылар саны – 1690

Үзәге – «Казан педагогика көллияте» урта һөнәри белем бирүче дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе, Побежимов урамы, 47а йорт, тел. 571-14-98

Сайлау участогына керәләр: Ленинград урамы, 15-23/37 йортлар, Максимов урамы, 37/23-45а йортлар, Побежимов урамы, 32-36 йортлар, Чапаев урамы, 5, 7, 11/43, 2/36-10 йортлар, Челюскин урамы, 24, 26, 28, 47 йортлар.

13 нче сайлау участогы
Сайлаучылар саны – 2367

Үзәге – «62 нче номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль мәгариф учреждениесе, Симонов урамы, 5 йорт, тел. 570-87-64

Сайлау участогына керәләр: Академик Павлов урамы, 15 йорт, Блочная урамы, Годовиков урамы, 21-29 йортлар, Лукин урамы, 8, 12-16, 24, 24а, 26 йортлар, Максимов урамы, 4/19-22 йортлар, Молодежная урамы, 11, 14, 16, 16а, 18, 24 йортлар, Молодежный тыкрыгы, Симонов урамы, 1 йорт.

14 нче сайлау участогы
Сайлаучылар саны – 2747

Үзәге – «123 нче номерлы һөнәр лицее» башлангыч һөнәри белем бирүче дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе, Дементьев урамы, 39 йорт, тел. 510-94-68

Сайлау участогына керәләр: Годовиков урамы, 14, 16 йортлар, Дементьев урамы, 33а йорт, Максимов урамы, 2, 4а йортлар, Молодежная урамы, 6-12, 14а, 14б йортлар.

15 нче сайлау участогы
Сайлаучылар саны – 1961

Үзәге – административ бина, Дементьев урамы, 70а йорт, тел. 571-93-92

Сайлау участогына керәләр: Дементьев урамы, 7, 7а, 27, 29а, 31, 31а, 33, 35, 37 йортлар.

16 нчы сайлау участогы
Сайлаучылар саны – 2653

Үзәге – «62 нче номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль мәгариф учреждениесе, Симонов урамы, 5 йорт, тел. 570-87-54

Сайлау участогына керәләр: Лукин урамы, 4 йорт, Максимов урамы, 1-7/6 йортлар, Трамвай урамы, 17 йорт.

17 нче сайлау участогы
Сайлаучылар саны – 2404

Үзәге – «37 нче номерлы гимназия» муниципаль мәгариф учреждениесе, Копылов урамы, 13 йорт, тел. 571-07-05

Сайлау участогына керәләр: Копылов урамы, 4, 12, 14, 18 йортлар, Лукин урамы, 1а, 3а йортлар, Побежимов урамы, 17, 37 йортлар.

18 нче сайлау участогы
Сайлаучылар саны – 2810

Үзәге – «145 нче номерлы лицей» муниципаль мәгариф учреждениесе, Дементьев урамы, 18 йорт, тел. 571-32-23

Сайлау участогына керәләр: Годовиков урамы, 4, 6, 15 йортлар, Дементьев урамы, 3, 3а, 5, 5а, 5б, 9, 18, 28 (1, 2 корпуслар) йортлар, О.Кошевой урамы, 20 йорт.

19 нчы сайлау участогы
Сайлаучылар саны – 2727

Үзәге – В.И.Ленин исемендәге мәдәни-ял комплексы, Копылов урамы, 2 йорт, тел. 8-9178511141

Сайлау участогына керәләр: Годовиков урамы, 7а-11 йортлар, Копылов урамы, 2 йорт, Лукин урамы, 2/15 йорт, О.Кошевой урамы, 2-18 йортлар, Побежимов урамы, 4-16б йортлар, Трамвай, Л.Чайкина урамнары.

20 нче сайлау участогы
Сайлаучылар саны – 2689

Үзәге – «112 нче номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль мәгариф учреждениесе, Лядов урамы, 16 йорт, тел. 571-26-11

Сайлау участогына керәләр: Белинский урамы, 11-21, 20-36 йортлар; Грабарский торак массивына караган Желябов, Заботин урамнары, Заботин тыкрыгы, Маркин, Огарев, Рыночная урамнары, Социалистическая урамы, 14-20а йортлар, Станиславский, Таймыр урамнары, Тар Урам, Челюскин урамы, 1-25, 27а, 31а, 35а йортлар, Шадрин урамы.

21 нче сайлау участогы
Сайлаучылар саны – 1766

Үзәге – Татарстан Республикасының балалар һәм яшүсмерләр техник иҗаты һәм мәгълүмати технологияләр республика үзәге, Социалистическая урамы, 5 йорт, тел. 571-14-78

Сайлау участогына керәләр: Белинский урамы, 8-12/8 йортлар, Индустрия урамы, 9-15/12 йортлар, Лядов урамы, 14 йорт, Социалистическая урамы, 7-11/14 йортлар, Челюскин урамы, 6/9, 10 йортлар.

22 нче сайлау участогы
Сайлаучылар саны – 2107

Үзәге – «10 нчы номерлы татар гимназиясе» муниципаль мәгариф учреждениесе, Копылов урамы, 11 йорт, тел. 571-07-15

Сайлау участогына керәләр: Белинский урамы, 3, 4, 4а, 5, 6, 7 йортлар, Индустрия урамы, 3-7 йортлар, Копылов урамы, 5/1 йорт, Лядов урамы, 2-12 йортлар, Социалистическая урамы, 3 йорт.

23 нче сайлау участогы
Сайлаучылар саны – 1970

Үзәге – «36 нчы номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль мәгариф учреждениесе, Лядов урамы, 7 йорт, тел. 571-35-96

Сайлау участогына керәләр: Копылов урамы, 1/2, 3/1 йортлар, Лядов урамы, 5, 9, 9а йортлар, Тимирязев урамы, 1а, 4-10/2 йортлар, Челюскин урамы, 4/13 йорт.

24 нче сайлау участогы
Сайлаучылар саны – 2225

Үзәге – «Авиатөзелеш» полиция бүлеге каршындагы хокук тәртибен саклау җәмәгать пункты, Белинский урамы, 39 йорт, тел.570-71-43

Сайлау участогына керәләр: Белинский урамы, 21а-41, 38 йортлар.

25 нче сайлау участогы
Сайлаучылар саны – 1811

Үзәге – Лаеш техник-икътисад техникумының Казан филиалы, Кече Армавир урамы, 31а йорт, тел. 571-30-69

Сайлау участогына керәләр: Грабарский торак массивына караган Ашхабад урамы, 1-19, 4-18 йортлар, Ашхабад тыкрыгы, Беломорск урамы, 39/30-67/20 йортлар, Зур Армавир урамы, 1-35, 4-30а йортлар, Глинка урамы, Җамбул урамы, 3-13, 4-14/61 йортлар, Дунай, Инвентарь урамнары, Караганда урамы, 1а-15/55, 2а йортлар, Краснодон урамы, 1/2-19/57, 6-30/55 йортлар, Кубань урамы, 25-81, 26-74/4 йортлар, Кубань тыкрыгы, Максимов урамы, 55-123/6, 84/19-128/8 йортлар, Кече Армавир урамы, 1/53-31а, 2а-24/43 йортлар, Обнорский, Панфиловчылар урамнары, Побежимов урамы, 61-145, 52-114 йортлар, Побежимов тыкрыгы, Аркылы Әстерхан урамы, 1а-15, 2а-12 йортлар, Райнис, Тюленин, Теләче, У.Громова урамнары, Үзәк Мариуполь урамы, 1а-29/37, 2а-16 йортлар, Л.Шевцова урамы.

26 нчы сайлау участогы
Сайлаучылар саны – 2830

Үзәге – «14 нче номерлы татар гимназиясе» муниципаль мәгариф учреждениесе, Беломорск урамы, 104 йорт, тел. 570-93-96

Сайлау участогына керәләр: Северный торак массивына караган Айдаров урамы, 75б-133а, 54/51-116 йортлар, Апрель урамы, 3 нче Армавир урамы, 15-29, 14/57-28 йортлар, Ашхабад урамы, 27/15-59/85, 24-74 йортлар, Багратион, Балтач урамнары, Балтыйк урамы, 33-63/34, 32-62 йортлар, Беломорск урамы, 58/31-108ж йортлар, Зур Армавир урамы, 39-79, 34-76 йортлар, Васнецов урамы, Җамбул урамы, 17-31, 18-32/149 йортлар, Дубинин урамы, 6, 8, 36, 38, 40, 42/1 йортлар, Краснодон урамы, 23-67, 36/64-66 йортлар, Красная Пресня урамы, Кутузов урамы, 17-25, 4-46 йортлар, Кутузов тыкрыгы, Кече Армавир урамы, 33-73/37, 28-48 йортлар, М.Бигиев урамы, 31-119 йортлар, Смоленск урамы, 3-17, 2а-18/58 йортлар, Сумская урамы, Үзәк Мариуполь урамы, 33-61/29 йортлар, Черняховский урамы, Чугуево урамы, 3-11, 4-16 йортлар, Шатура урамы, 115-189, 56а-128 йортлар, 2 нче Шатура урамы.

27 нче сайлау участогы
Сайлаучылар саны – 2616

Үзәге – «14 нче номерлы татар гимназиясе» муниципаль мәгариф учреждениесе, Луначарский урамы, 9 йорт, тел. 571-62-48

Сайлау участогына керәләр: Северный торак массивына караган 1 нче Армавир урамы, 13а-37а, 18/69-36 йортлар, Баулы урамы, Зур Армавир урамы, 81б-171, 80-166а йортлар, Краснодон урамы, 71-189а, 68-182 йортлар, Краснодон тыкрыгы, Краснокамск урамы, Л.Черкасов урамы, 41, 43/66, 59, 40-52а йортлар, Литвинов урамы, 49-73, 38-68/82 йортлар, Луначарский урамы, 5/13-31, 28/2-44а йортлар, М.Бигиев урамы, 30/63-60/19 йортлар, Кече Армавир урамы, 77-173, 62-152, 172 йортлар, Набережная урамы, Смоленск урамы, 20-142 йортлар, Собинов урамы, 49-75, 56/133-76/68 йортлар, Тбилиси урамы, 1/87, 2а-10б йортлар, Тренев, Турский, Успенский урамнары, Үзәк Мариуполь урамы, 63/30-141 йортлар, Чугуево урамы, 15-23, 20-30 йортлар.

28 нче сайлау участогы
Сайлаучылар саны – 2877

Үзәге – «14 нче номерлы татар гимназиясе» муниципаль мәгариф учреждениесе, Луначарский урамы, 9 йорт, тел. 571-62-48

Сайлау участогына керәләр: Северный торак массивына караган Ашхабад урамы, 63-147, 155, 187, 189, 78-194 йортлар, Батуми, Воронихин, Гафиатуллин, Маршал Говоров, Гори урамнары, Д.Давыдов урамы, 58-154 йортлар, Джапаридзе урамы, Дубинин урамы, 59-159, 46-146 йортлар, Ермолова, Жигули, Карамзин урамнары, Кутузов урамы, 29-125, 52-134 йортлар, Луначарский урамы, 37, 73, 73а, 73б, 73в, 75, 75а, 75б, 75в, 77, 50, 56/22, 58, 82/24 йортлар, М.Бигиев урамы, 62-124 йортлар, Симферополь урамы, Смоленск урамы, 21-141а йортлар, Собинов урамы, 83а, 80-98/44 йортлар, Ставрополь, Сухуми урамнары, Тбилиси урамы, 3-71, 12-58 йортлар, Ялта урамы.

29 нчы сайлау участогы
Сайлаучылар саны – 1784

Үзәге – «115 нче номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль мәгариф учреждениесе, Беломорск урамы, 144 йорт, тел. 571-86-72

Сайлау участогына керәләр: Северный торак массивына караган Ак каен урамы, 2 нче Бадаев урамы, 4-22 йортлар, Бадаев тыкрыгы, Д.Давыдов урамы, 81/98-143 йортлар, Камышлы урамы, 59-115, 60-120 йортлар, Литвинов урамы, 111-175, 90/37-158 йортлар, Луначарский урамы, 77, 77а-135, 177, 90-182 йортлар, Пожарский урамы, 92-106, 93-113а йортлар, Сентябрь урамы, Собинов урамы, 123-155, 122-198 йортлар, Суворов урамы, 75-153, 54-136 йортлар, Харьков урамы, 67-101, 72-98 йортлар, Л.Черкасов урамы, 97-187, 4, 4а, 4б, 4в, 4д, 4ж, 6а, 6б, 6в, 6г, 8, 8в, 8г, 8д, 10, 10а, 10б, 10в, 10г, 10е, 178-190 йортлар, Шомыртлы урамы.

30 нчы сайлау участогы
Сайлаучылар саны – 2888

Үзәге – «115 нче номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль мәгариф учреждениесе, Беломорск урамы, 144 йорт, тел. 571-86-72

Сайлау участогына керәләр: Северный торак массивына караган Айдаров урамы, 137-187, 118-158 йортлар, Арбат урамы, Бадаев урамы, 1-21а, 2-24а йортлар, 2 нче Бадаев урамы, 1-21 йортлар, Балакирев урамы, Беломорск урамы, 114-164 йортлар, М.Бигиев урамы, 125-165, 128-136 йортлар, Вильямс, Волгодонск, Волхов, Гидрострой урамнары, Д.Давыдов урамы, 1-75, 4-56/139 йортлар, Добролюбов урамы, Дубинин урамы, 7-55, 14-32 йортлар, Зәй урамы, Камышлы урамы, 17-55, 4-58 йортлар, Левитан, Луганск, Мамин-Сибиряк, Мәләкәс, Минин, А.Нәвои урамнары, С.Перовская урамы, 3-85, 4-86а йортлар, Пестель урамы, 10-92 йортлар, Пожарский урамы, 3-91, 4-90а йортлар, Пожарский тыкрыгы, Пятигорск урамы, 3-41, 2/45-26 йортлар, Суворов урамы, 3-73а, 8-52 йортлар, Харьков урамы, 7-61а, 24-54а йортлар, Чита урамы, Шатура урамы, 201-267/20, 130-212/22 йортлар, Шаумян, Я.Купала урамнары.

31 нче сайлау участогы
Сайлаучылар саны – 2269

Үзәге – «134 нче номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль мәгариф учреждениесе, Котовский урамы, 2 йорт, тел. 571-86-82

Сайлау участогына керәләр: Яңа Каравай торак массивына караган Бадаев урамы, 23-47а, 26/39-58 йортлар, Беломорск урамы, 174/1-214 йортлар, Бестужев, В.Котик, Зелинский, Котовский, Моисеев урамнары, 1 нче Муром урамы, 4-120 йортлар, 1 нче Пермь, 2 нче Пермь урамнары, С.Перовская урамы, 87-115, 88-134/36 йортлар, Пестель урамы, 3-107а, 94-110 йортлар, Петляков урамы, Пятигорск урамы, 63-107/47, 28/30-64 йортлар, Рига, С.Ковалевская, Серафимович, И.Федоров урамнары, Шатура урамы, 269-303, 220-246 йортлар.

32 нче сайлау участогы
Сайлаучылар саны – 2455

Үзәге – «5 нче номерлы татар гимназиясе» муниципаль мәгариф учреждениесе, Гудованцев урамы, 26 йорт, тел. 571-78-86

Сайлау участогына керәләр: Яңа Каравай торак массивына караган Беломорск урамы, 69 йорт, Гудованцев урамы, 2-110 йортлар, 1 нче Муром урамы, 1/216-121 йортлар, 2 нче Муром, 3 нче Муром, 4 нче Муром, 5 нче Муром урамнары, С.Перовская урамы, 136-150 йортлар, Пятигорск урамы, 119/47-127, 70-90/50 йортлар, Шатура урамы, 250, 252 йортлар.

35 нче сайлау участогы
Сайлаучылар саны – 821

Үзәге – «112 нче номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль мәгариф учреждениесе, Лядов урамы, 16 йорт, тел. 571-26-11

Сайлау участогына керәләр: Восход урамы, 45 йорт, Теплично-Комбинатская, Тэцевская урамнары.

36 нчы сайлау участогы
Сайлаучылар саны – 2643

Үзәге – «77 нче номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль мәгариф учреждениесе, Айдаров урамы, 2 йорт, тел. 570-86-68

Сайлау участогына керәләр: Айдаров урамы, 4, 6, 7, 8а йортлар, Ленинград урамы, 60, 60б йортлар, Лукин урамы, 37, 41- 47а йортлар.

37 нче сайлау участогы
Сайлаучылар саны – 2432

Үзәге – «147 нче номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль мәгариф учреждениесе, Кадыш торак массивы, Р.Зорге урамы, 2/5 йорт, тел. 570-33-25

Сайлау участогына керәләр: Кадыш торак массивына караган Г.Камал, Заречная, Зеленая, Калинин, Колодезная, Нагорная, Новая, Почта, Р.Зорге, Совет, Татарстан, Толстой, Школьная, Чехов, Чапаев урамнары; Борисоглебский торак массивына караган Авиатөзүчеләр, Гагарин, Дачная, Завод, Заречная, Зеленая, Ивовая, Иванычев, Кадыш, Колхоз, Ленин, Луговая, Малая Заречная, Молодежная, Новая, Озерная, Октябрь, Производственная, Переломная, Җиңү, Поперечная, Рабочая, 2 нче Рабочая, 3 нче Рабочая, Речная, Северная, Совет, Сухорецкая, Степная, Садовая, Торфяная, Школьная, Шоссе, Южная урамнары; Щербаково торак массивына караган Березовая, Газ, Дачная, Зеленая, Кадыш, Лесная, Магистраль, Молодежная, Новая, Обочная, Ольховая, Осиновая, Рабочая, Речная, Садовая, Центральная урамнары; Голубое Озеро торак массивына караган Лесная, Центральная урамнары.

38 нче сайлау участогы
Сайлаучылар саны – 458

Үзәге – «Крутушка шифаханәсе» медицина-социаль реабилитация үзәге, Крутушка поселогы, Центральная урамы, 1 йорт, тел.89509495827

Сайлау участогына керәләр: Крутушка торак массивына караган Центральная урамы, «Крутушка шифаханәсе» медицина-социаль реабилитация үзәге.

39 нчы сайлау участогы
Сайлаучылар саны – 2374

Үзәге – «62 нче номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль мәгариф учреждениесе, Симонов урамы, 5 йорт, тел. 570-87-64

Сайлау участогына керәләр: Академик Павлов урамы, 19, 21, 23, 23а, 25, 25а йортлар.

40 нчы сайлау участогы
Сайлаучылар саны – 2355

Үзәге – «33 нче номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль мәгариф учреждениесе, Симонов урамы, 17 йорт, тел. 524-04-34

Сайлау участогына керәләр: Беломорск урамы, 6, 8/18, 10/19, 18а йортлар, Ленинград урамы, 31 йорт, Симонов урамы, 15 йорт, Чапаев урамы, 20/19, 21 йортлар, Челюскин урамы, 44, 46, 46а, 48 йортлар.

41 нче сайлау участогы
Сайлаучылар саны – 1904

Үзәге – «117 нче номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль мәгариф учреждениесе, Дунай урамы, 16 йорт, тел. 571-41-64

Сайлау участогына керәләр: Грабарский торак массивына караган Кольцевая урамындагы шәхси йортлар, Лечебная урамы, Побежимов урамы, 37-57а, Социалистическая урамы, 2, 8/10.

ВАХИТОВ РАЙОНЫ

42 нче сайлау участогы
Сайлаучылар саны – 1407

Үзәге – «А.Н.Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты – КАИ» югары һөнәри белем бирүче федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе, К.Маркс урамы, 10 йорт, тел. 231-01-84

Сайлау участогына керәләр: Бехтерев, Батурин урамнары, Большая Красная урамы, 1а, 1б, 3, 3а, 5, 7/9, 13, 4, 6, 8, 10, 14, 16, 18, 22, 22а йортлар, Дзержинский урамы, 3, 5, 9/1, 11а, 11/2, 13, 15, 17 йортлар, З.Космодемьянская урамы, К.Маркс урамы, 3, 11, 13, 8/13, 12, 14, 16, 16а, 18 йортлар, К.Фукс урамы, 9, 11 йортлар, Миславский урамы, 11 йорт, Казансу буе, Нагорная урамнары, Тельман урамы, 21, 23, 29 йортлар, Федосеев, Япеев урамнары.

43 нче сайлау участогы
Сайлаучылар саны – 2196

Үзәге – «116 нчы номерлы лицей» муниципаль мәгариф учреждениесе, Жуковский урамы, 18 йорт, тел.: 238-35-86, 238-39-48

Сайлау участогына керәләр: Адамюк урамы, 4 йорт, Большая Красная урамы, 17/10, 21, 23, 27, 29, 29а, 39, 41, 51, 32, 36а, 48, 50, 54 йортлар, Гоголь урамы, 19, 21, 21а, 23, 23а, 25, 25а, 27, 27а, 29, 31, 33 йортлар, Дзержинский урамы, 23, 27, 27а йортлар, Жуковский урамы, 21, 23, 23а, 25, 27, 29, 12/46, 16, 18, 20, 24, 26, 28, 28а йортлар, К.Фукс урамы, 2а, 4 йортлар, яңадан кертелүче 10 йорт, 12 йорт, К.Маркс урамы, 23/6, 25, 29, 29/14, 43, 45, 47, 47а, 47б, 47в, 24, 34 йортлар, Касаткин урамы, Лобачевский урамы, 6, 8, 10, 12, 12а йортлар, Малая Красная урамы, 3, 5, 7, 9/6, 11/1, 13, 23, 4, 6, 8, 10, 12, 14, 16 йортлар, Пушкин урамы, 68, 76, 78а, 84 йортлар, Театр урамы, 1/29, 3, 5, 13 йортлар, Тельман урамы, 5, 9, 13, 15, 2, 14, 16, 18а, 26, 28, 30, 32, 34, 36, 38, 40, 42 йортлар.

44 нче сайлау участогы
Сайлаучылар саны – 2021

Үзәге – «Россия дәүләт сәүдә-икътисад университеты» югары һөнәри белем бирүче дәүләт мәгариф учреждениесенең Казан институты (филиалы), Кремль урамы, 25/22 йорт, тел.: 292-78-25, 274-93-97

